**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының коррупциягә каршы көрәшү мәсьәләләре буенча аерым указларына үзгәрешләр кертү турында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр бирү турында» 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-702 номерлы Указы белән расланган (Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 1 ноябрендәге ПУ-711 номерлы, 2012 елның 16 маендагы ПУ-343 номерлы, 2013 елның 22 апрелендәге ПУ-328 номерлы, 2014 елның 24 сентябрендәге ПУ-920 номерлы, 2015 елның 23 мартындагы ПУ-308 номерлы, 2015 елның 13 октябрендәге ПУ-988 номерлы, 2016 елның 18 мартындагы ПУ-265 номерлы, 2017 елның 11 февралендәге ПУ-123 номерлы, 2017 елның 11 декабрендәге ПУ-1092 номерлы, 2020 елның 4 мартындагы ПУ-137 номерлы, 2021 елның 3 июнендәге ПУ-427 номерлы указлары һәм Татарстан Республикасы Рәисенең 2023 елның 23 сентябрендәге 667 номерлы Указы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр бирү турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Әлеге Нигезләмәнең 5, $5^1$ һәм 6 пунктларында каралган белешмәләр, әлеге пунктның икенче – дүртенче абзацларында каралган очраклардан тыш, Татарстан Республикасы дәүләт органының дәүләт хезмәте һәм кадрлар мәсьәләләре буенча бүлекчәсенә (алага таба – Татарстан Республикасы дәүләт органының кадрлар хезмәте) тапшырыла.

Әлеге Нигезләмәнең 5, $5^1$ һәм 6 пунктларында каралган белешмәләр Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясендә Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан вазыйфага билгеләп куела һәм вазыйфадан азат ителә торган граждан хезмәте вазыйфалары биләүне дәгъвалаучы гражданнар, шулай ук әлеге граждан хезмәте вазыйфаларын биләүче граждан хезмәткәрләре тарафыннан Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы

Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаментына (алга таба – Департамент) тапшырыла.

Әлеге Нигезләмәнең 5, $5^1$ һәм 6 пунктларында каралган белешмәләр, Татарстан Республикасының Россия Федерациясендәге, Россия Федерациясе субъектындагы, БДБ илләрендәге, чит илләрдәге вәкиллекләрендә, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты составына керми торган республика башкарма хакимият органнарында Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан вазыйфага билгеләп куела һәм вазыйфадан азат ителә торган граждан хезмәте вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, шулай ук әлеге граждан хезмәте вазыйфаларын Татарстан Республикасы Рәисенең Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсендә (алга таба – Идарә) биләүче гражданнар тарафыннан бирелә.

Әлеге Нигезләмәнең 5, $5^1$ һәм 6 пунктларында каралган белешмәләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан эшкә билгеләп куела һәм аннан азат ителә торган гражданнар, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының дәүләт хезмәте һәм кадрлар мәсьәләләре бүлекчәсендә әлеге граждан хезмәте вазыйфаларын биләүче гражданнар тарафыннан бирелә.»;

б) 9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Граждан яисә граждан хезмәткәре аның тарафыннан Департаментка, Идарәгә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының дәүләт хезмәте һәм кадрлар мәсьәләләре буенча бүлекчәсенә, Татарстан Республикасы дәүләт органының кадрлар хезмәтенә биргән белешмәләрдә нинди дә булса мәгълүматлар чагылдырылмаган яисә тулысынча чагылдырылмаган яки хаталар булуын ачыклаган очракта, алар әлеге Нигезләмә билгеләгән тәртиптә анықланган белешмәләрне бирергә хокуклы.

Граждан хезмәткәре тарафыннан әлеге Нигезләмәнең 3 пунктының икенче абзацы нигезендә анықланган белешмәләрне белешмәләр бирелгән көннән бер ай дәвамында бирә ала. Вазыйфалар исемлегенә кертелгән вазыйфаны биләүгә кандидат әлеге Нигезләмәнең 3 пунктының өченче абзацы нигезендә анықланган белешмәләрне белешмәләр бирелгән көннән бер ай дәвамында бирә ала. Граждан хезмәткәре анықланган белешмәләрне әлеге Нигезләмәнең 4 пунктында күрсәтелгән вакыт узганнан соң бер ай дәвамында бирә ала.»;

в) 15 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында Департаментка, Идарәгә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының дәүләт хезмәте һәм кадрлар мәсьәләләре буенча бүлекчәсенә, Татарстан Республикасы дәүләт органының кадрлар хезмәтенә белешмә биргән граждан яисә Вазыйфалар исемлегенә кертелгән вазыйфа биләүгә кандидат граждан хезмәте вазыйфасына билгеләнмәгән очракта, бу

белешмәләр аларның язма гаризасы буенча башка документлар белән бергә кире кайтарып бирелә.».

2. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләрне Татарстан Республикасы дәүләт органнарының рәсми сайтларында урнаштыру һәм бу белешмәләрне бастырып чыгару өчен массакүләм мәгълүмат чараларына бирү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2010 елның 19 апрелендәге ПУ-237 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 1 ноябрендәге ПУ-711 номерлы, 2012 елның 16 маендагы ПУ-343 номерлы, 2013 елның 14 августындагы ПУ-761 номерлы, 2014 елның 20 августындагы ПУ-797 номерлы, 2015 елның 23 мартындагы ПУ-308 номерлы, 2016 елның 18 мартындагы ПУ-265 номерлы, 2021 елның 3 июнендәге ПУ-427 номерлы указлары һәм Татарстан Республикасы Рәисенең 2023 елның 23 сентябрендәге 667 номерлы Указы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләрне Татарстан Республикасы дәүләт органнарының рәсми сайтларында урнаштыру һәм бу белешмәләрне бастырып чыгару өчен массакүләм мәгълүмат чараларына бирү тәртибе турында нигезләмәгә, 5 пунктының «б» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«б) Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясендә Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан вазыйфага билгеләп куела һәм вазыйфадан азат ителә торган граждан хезмәте вазыйфалары биләүче дәүләт граждан хезмәткәрләре биргән белешмәләрне тикшерү Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты тарафыннан тәэмин ителә;

Татарстан Республикасының Россия Федерациясендәге, Россия Федерациясе субъектындагы, БДБ илләрендәге, чит илләрдәге вәкиллекләрендә, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты составына керми торган республика башкарма хакимият органнарында Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан вазыйфага билгеләп куела һәм вазыйфадан азат ителә торган граждан хезмәте вазыйфаларын биләүче дәүләт граждан хезмәткәрләре биргән белешмәләрне тикшерү Татарстан Республикасы Рәисенең Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсе тарафыннан тәэмин ителә;».

3. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм

Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан бирелә торган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәвен тикшерү турында» 2010 елның 1 ноябрендәге ПУ-711 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2012 елның 16 маендагы ПУ-343 номерлы, 2013 елның 6 ноябрендәге ПУ-1084 номерлы, 2014 елның 24 сентябрендәге ПУ-920 номерлы, 2015 елның 23 мартындагы ПУ-308 номерлы, 2015 елның 13 октябрендәге ПУ-988 номерлы, 2017 елның 11 декабрендәге ПУ-1092 номерлы, 2020 елның 4 мартындагы УП-137 номерлы, 2021 елның 3 июнендәге ПУ-427 номерлы, 2022 елның 20 декабрендәге ПУ-905 номерлы указлары һәм Татарстан Республикасы Рәисенең 2023 елның 23 сентябрендәге 667 номерлы Указы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан бирелә торган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәвен тикшерү турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 5 пунктның «а» пунктчасында «башкарылучы» сүзеннән соң «Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясендә» сүзләрен өстәргә»;

б) түбәндәге эчтәлекле $5^1$ пунктын өстәргә:

«$5^1$. Татарстан Республикасы Рәисенең Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсе (алга таба – Идарә) Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе карары нигезендә түбәндәгеләрне тикшерүне уздыра:

а) Татарстан Республикасының Россия Федерациясендәге, Россия Федерациясе субъектындагы, БДБ илләрендәге, чит илләрдәге вәкиллекләрендә, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты составына керми торган республика башкарма хакимият органнарында Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан вазыйфага билгеләп куела һәм вазыйфадан азат ителә торган граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәре турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында бирелгән белешмәләрнең, шулай ук әлеге гражданнар тарафыннан Россия Федерациясе норматив хокукый актлары нигезендә бирелә торган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын;

б) әлеге пунктның «а» пунктчасында күрсәтелгән Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүче граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында бирелгән белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын;

в) әлеге пунктның «а» пунктчасында күрсәтелгән Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүче гражданнар тарафыннан хезмәт тәртибенә таләпләрнең үтәлүен.»;

в) 12 пунктта «Департамент,» сүзеннән соң «Идарә,» сүзен өстәргә;

г) 13 пунктта «Департамент,» сүзеннән соң «Идарә,» сүзен өстәргә;

д) 15 пунктта:

түбәндәге эчтәлекле яңа өченче абзац өстәргә:

«әлеге Нигезләмәнең $5^1$ пунктында күрсәтелгән гражданнарга һәм граждан хезмәткәрләренә карата оператив-эзләү чараларын уздыру турында сорату юллау турындагы тәкъдимне Идарә әзерли.»;

өченче һәм дүртенче абзацларны тиешенчә дүртенче һәм бишенче абзацлар дип санарга;

бишенче абзацны алтынчы абзац дип санарга һәм анда «Департамент» сүзен «Идарә» сүзенә алмаштырырга;

е) 17 пунктта «Департамент җитәкчесе,» сүзләреннән соң «Идарә башлыгы,» сүзләрен өстәргә»;

ж) 18 пунктта «Департамент,» сүзеннән соң «Идарә,» сүзен өстәргә;

з) 19 пунктның «в» пунктчасында «Департамент,» сүзеннән соң «Идарә,» сүзен өстәргә;

и) 22 пунктта «Департамент җитәкчесе,» сүзләреннән соң «Идарә башлыгы,» сүзләрен өстәргә»;

к) 24 пунктта «Департамент,» сүзләреннән соң «Идарә,» сүзен өстәргә;

л) 27 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-702 номерлы Указы нигезендә Идарәгә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының кадрлар хезмәтенә бирелгән керемнәр турында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләрнең төп нөсхәләре календарь ел тәмамланганнан соң шәхси эшләренә теркәү өчен Татарстан Республикасы дәүләт органнарының кадрлар хезмәтенә җибәрелә. Күрсәтелгән белешмәләрнең күчермәләре Идарәдә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының кадрлар хезмәтендә өч ел буена саклана, аннан соң архивка тапшырыла.»;

м) 28 пунктта «Департаментта,» сүзеннән соң «Идарәдә,» сүзен өстәргә.

4. Татарстан Республикасы Президентының «Коррупциягә каршы тору турында» Федераль законның һәм «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнары аларның керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында» Федераль законның аерым нигезләмәләрен гамәлгә ашыру чаралары турында һәм Татарстан Республикасы Президентының коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча аерым указларына үзгәрешләр кертү хакында» 2013 елның 6 ноябрендәге ПУ-1084 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2014 елның 20 августындагы ПУ-797 номерлы, 2015 елның 23 мартындагы ПУ-308 номерлы, 2016 елның 18 мартындагы ПУ-265 номерлы, 2017 елның 2 декабрендәге ПУ-1042 номерлы, 2021 елның 3 июнендәге ПУ-427 номерлы һәм 2022 елның 20 декабрендәге ПУ-905 номерлы указлары һәм Татарстан

Республикасы Рәисенең 2023 елның 23 сентябрендәге 667 номерлы Указы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 1 пунктта:

«а» пунктчасында:

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясендә Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан вазыйфага билгеләп куела һәм вазыйфадан азат ителә торган һәм алар буенча вәкаләтләр башкару керемнәре турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында, шулай ук хатыны (ире) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр бирүне таләп итә торган дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүче затларның;»;

түбәндәге эчтәлекле яңа дүртенче абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасының Россия Федерациясендәге, Россия Федерациясе субъектындагы, БДБ илләрендәге, чит илләрдәге вәкиллекләрендә, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты составына керми торган республика башкарма хакимият органнарында Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан вазыйфага билгеләп куела һәм вазыйфадан азат ителә торган һәм алар буенча вәкаләтләр башкару керемнәре турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында, шулай ук хатыны (ире) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр бирүне таләп итә торган дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүче затларның;»;

дүртенче һәм бишенче абзацларны тиешенчә бишенче һәм алтынчы абзацлар дип санарга;

алтынчы абзацны җиденче абзац дип санарга һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«әлеге пунктчаның икенче, өченче, дүртенче һәм алтынчы абзацларында күрсәтелгән затларның хатыннары (ирләре) һәм балигъ булмаган балаларының;»;

«б» пунктчасының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан вазыйфага билгеләп куела һәм вазыйфадан азат ителә торган һәм алар буенча вәкаләтләр башкару керемнәре турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында, шулай ук хатыны (ире) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турында, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр бирүне таләп итә торган дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүче затларның;»;

«в» пунктчасының икенче абзацында «а» пунктчасының өченче абзацында күрсәтелгән затлар» сүзләрен «а» пунктчасының өченче һәм дүртенче абзацында күрсәтелгән затлар» сүзләренә алмаштырырга;

б) 5 пунктта:

«а» һәм «б» пунктларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) Татарстан Республикасы Рәисенең Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсе әлеге Указның 1 пунктының «а» пунктчасындагы икенче һәм дүртенче абзацларында күрсәтелгән затларның чыгымнарын, аларның әлеге Указның 2 пунктында күрсәтелгән хатыннары (ирләре) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнарын контрольдә тота;

б) Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты әлеге Указның 1 пунктының «а» пунктчасындагы өченче һәм алтынчы абзацларында күрсәтелгән затларның чыгымнарын, шулай ук аларның хатыннары (ирләре) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнарын контрольдә тота;»;

в) 9 пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Россия Федерациясе Президентының «Коррупциягә каршы көрәшү турында» Федераль законның аерым нигезләмәләрен гамәлгә ашыру чаралары турында» 2013 елның 2 апрелендәге 309 номерлы Указы белән расланган Исемлекнең 8 пункты нигезендә коррупциягә каршы көрәшү максатларында тикшерүләр уздырганда кредит оешмаларына, Россия Федерациясе салым органнарына, күчемсез милеккә һәм аның белән бәйле эш йөртүләргә хокукларны дәүләт теркәвенә алу органнарына һәм цифрлы финанс активлары чыгарыла торган мәгълүмат системалары операторларына соратулар юллау вәкаләтләре (шул исәптән, коррупциягә каршы көрәшү өлкәсендә «Посейдон» дәүләт мәгълүмат системасын, шул исәптән соратулар юллау өчен файдаланып) бирергә:»;

«а» пунктчасының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«әлеге Указның 1 пункты «а» пунктчасының икенче, өченче һәм дүртенче абзацларында күрсәтелгән затлар, шулай ук аларның хатыннары (ирләре) һәм балигъ булмаган балалары;»;

г) 10 пунктта «1 пункты «а» пунктчасының бишенче абзацында күрсәтелгән затлар» сүзләрен «1 пункты «а» пунктчасының алтынчы абзацында күрсәтелгән затлар» сүзләренә алмаштырырга.

5. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында Коррупциягә каршы көрәшү эшен координацияләү комиссиясе турында» 2015 елның 13 октябрендәге ПУ-986 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2015 елның 5 декабрендәге ПУ-1163 номерлы, 2016 елның 18 мартындагы ПУ-265 номерлы, 2016 елның 8 октябрендәге ПУ-914 номерлы, 2017 елның 21 августындагы ПУ-717 номерлы, 2017 елның 2 декабрендәге ПУ-1042 номерлы, 2017 елның 11 декабрендәге ПУ-1092 номерлы, 2018 елның 9 февралендәге ПУ-151 номерлы, 2018 елның 31 мартындагы ПУ-273 номерлы, 2018 елның 8 августындагы ПУ-557 номерлы, 2020 елның 2 маендагы ПУ-266 номерлы, 2021 елның 2 июнендәге ПУ-425 номерлы, 2022 елның 10 мартындагы ПУ-196 номерлы, 2022 елның 17 декабрендәге ПУ-889 номерлы,

2022 елның 20 декабрендәге ПУ-905 номерлы указлары һәм 2023 елның 23 сентябрендәге 667 номерлы Указы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Татарстан Республикасында Коррупциягә каршы көрәшү эшен координацияләү комиссиясенең Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең кайбер вазыйфаларын биләүче затларның хезмәт (вазыйфаи) тәртибенә таләпләрне үтәвенә һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салуга, шулай ук гражданнарның һәм оешмаларның кайбер мөрәҗәгатьләренә кагылышлы мәсьәләләрне карау тәртибе турындагы нигезләмәне расларга (3 нче кушымта).»;

б) Татарстан Республикасында Коррупциягә каршы көрәшү эшен координацияләү комиссиясе турында нигезләмәдә:

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Комиссия үз эшен Россия Федерациясе Президентының Дәүләт хезмәте, кадрлар һәм коррупциягә каршы көрәшү мәсьәләләре буенча идарәсе белән хезмәттәшлектә алып бара.»;

түбәндәге эчтәлекле $4^1$ пункты өстәргә:

«$4^1$. Комиссия Татарстан Республикасының Россия Федерациясендәге, Россия Федерациясе субъектындагы, БДБ илләрендәге, чит илләрдәге вәкиллекләрендә, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты составына керми торган республика башкарма хакимият органнарында Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан вазыйфага билгеләп куела һәм вазыйфадан азат ителә торган граждан хезмәте вазыйфаларын биләүче затларның хезмәт тәртибенә һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салуга таләпләрне үтәү буенча комиссиягә йөкләнгән функцияләрне башкара һәм Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан билгеләнгән тәртиптә тиешле мәсьәләләрне карап тикшерә.»;

6 пунктка түбәндәге эчтәлекле «$д^2$» пунктчасы өстәргә:

«$д^2$) Татарстан Республикасының Россия Федерациясендәге, Россия Федерациясе субъектындагы, БДБ илләрендәге, чит илләрдәге вәкиллекләрендә, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты составына керми торган республика башкарма хакимият органнарында Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан вазыйфага билгеләп куела һәм вазыйфадан азат ителә торган граждан хезмәте вазыйфаларын биләгән затларның коррупциягә каршы көрәшү максатларында кертелгән тыюларны, чикләүләрне һәм таләпләрне үтәвенә кагылышлы мәсьәләләрне карап тикшерә;»;

15 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15. Әлеге Нигезләмәнең 6 пункты «д», «$д^1$» һәм «$д^2$» пунктчаларында күрсәтелгән мәсьәләләрне хәл итү өчен Комиссия карары белән Комиссия президиумы төзелә.»;

в) Татарстан Республикасында Коррупциягә каршы көрәшү эшен координацияләү комиссиясе (алга таба шулай ук – Комиссия) составында:

Комиссия составыннан Ф.Ә. Әгълиуллинны, Э.С. Каминскийны, Т.Д. Нагумановны, А.В. Хохоринны, Н.К. Шиминаны чыгарырга;

Комиссия составына кертергә:

Гыйлаҗев Илгиз Идрис улын – Татарстан Республикасы Конституция советы Рәисен (килешү буенча);

Гыйльметдинов Азат Мансур улын – Татарстан Республикасы Югары Суды Рәисен (килешү буенча);

Кадыйров Азат Рифгать улын – Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрын;

Корманов Мидхәт Мәзгут улын – «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесенең конституциячел һәм административ хокук кафедрасы профессоры, юридик фәннәр докторын (килешү буенча);

Садретдинов Дамир Рөстәм улын – Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрын (килешү буенча);

Хәбетдинова Гүзәл Мөдәррис кызын – Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесен (килешү буенча);

Комиссия әгъзасы И.И. Бикеевның вазыйфасы атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «В.Г. Тимирясов исемендәге Казан инновация университеты (Икътисад, идарә һәм хокук институты)» югары белем бирү хосусый мәгариф учреждениесенең беренче проректоры, фәнни эш буенча проректоры, профессор, юридик фәннәр докторы, Россия Федерациясе Юстиция министрлыгы тарафыннан норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру вәкаләте бирелгән бәйсез эксперт (килешү буенча)»;

г) Татарстан Республикасында коррупциягә каршы көрәшү эшен координацияләү комиссиясе тарафыннан Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәвенә һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салуга кагылышлы мәсьәләләрне карау тәртибе хакында нигезләмәне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«Татарстан Республикасында Коррупциягә каршы көрәшү эшен координацияләү комиссиясенең Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең кайбер вазыйфаларын биләүче затларның хезмәт (вазыйфаи) тәртибенә таләпләрне үтәвенә һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салуга, шулай ук гражданнарның һәм оешмаларның кайбер мөрәҗәгатьләренә кагылышлы мәсьәләләрне карау тәртибе турында нигезләмә**

1. Әлеге Нигезләмәдә Татарстан Республикасында Коррупциягә каршы көрәшү эшен координацияләү комиссиясе (алга таба – Комиссия) тарафыннан түбәндәгеләрне карап тикшерү тәртибе билгеләнә:

а) коррупциягә каршы көрәшү максатларында «Коррупциягә каршы көрәшү турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, башка федераль законнар нигезендә билгеләнгән чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау яисә җайга салу буенча таләпләрне (алга таба – хезмәт тәртибенә куелган таләпләр һәм (яисә) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча таләпләр) түбәндәгеләр тарафыннан үтәүгә, вазыйфалар башкаруга кагылышлы мәсьәләләрне:

Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары биләүче затлар тарафыннан: Татарстан Республикасы Премьер-министры, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе, Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасары, Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы министры, Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Россия Федерациясендә Татарстан Республикасының Вәкаләтле вәкиле, Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты Җитәкчесе, Татарстан Республикасы министры, Татарстан Республикасы дәүләт комитеты рәисе, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте башка органы җитәкчесе – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты әгъзасы, Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил – Татарстан Республикасы Рәисе ярдәмчесе, Татарстан Республикасы Хисап палатасы рәисе, Татарстан Республикасы Хисап палатасы рәисе урынбасары, Татарстан Республикасы Хисап палатасы аудиторы, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе Рәисе, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе Рәисе урынбасары, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе секретаре, Татарстан Республикасы Конституция советы Рәисе, Татарстан Республикасы Конституция советы әгъзасы (алга таба – Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче зат);

Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан вазыйфага билгеләп куела һәм вазыйфадан азат ителә торган аерым Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүче затлар: Россия Федерациясе субъектында, БДБ илләрендә, чит илләрдә Татарстан Республикасы вәкиле, Россия Федерациясендә Татарстан Республикасының Вәкаләтле вәкиленең беренче урынбасары, Россия Федерациясендә Татарстан Республикасының Вәкаләтле вәкиле урынбасары, Россия Федерациясе субъектында, БДБ илләрендә, чит илләрдә Татарстан Республикасы вәкиле урынбасары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты составына керми торган республика башкарма хакимият органнары җитәкчесе (алга таба шулай ук – дәүләт хезмәткәре);

б) Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасы биләүче затның, дәүләт хезмәткәренең чыгымнарына контроль ясау барышында алынган нәтиҗәләр;

в) әлеге Нигезләмәнең 1 пункты «а» пунктчасының өченче абзацында күрсәтелгән Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын биләүче гражданның (алга таба – граждан) Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтеннән азат ителгән көннән ике ел узганчы, коммерциячел яисә коммерциячел булмаган оешмада, әлеге оешмага дәүләт идарәсе буенча аерым функцияләр аның вазыйфаи бурычларына кергән очракта, вазыйфа биләүгә һәм (яисә) әлеге оешмада гражданлык-хокукый шартнамә нигезендә эш башкаруга (әлеге оешмага хезмәт күрсәтүгә) ризалык бирүе турында мөрәҗәгате;

г) коммерциячел яисә коммерциячел булмаган оешманың, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасы биләгән чорда аның вазыйфаи бурычларына әлеге оешмага дәүләт идарәсе буенча аерым функцияләр кергән граждан белән әлеге оешмада эш башкару (әлеге оешмага хезмәт күрсәтү) турында хезмәт шартнамәсе һәм (яисә) гражданлык-хокукый шартнамә төзү турында хәбәрнамәсе.

2. Комиссия утырышы уздыру өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

а) Комиссия рәисенең түбәндәгеләр нигезендә кабул ителгән карары:

Татарстан Республикасы Президентының 2011 елның 22 апрелендәге 233 номерлы Указы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан бирелгән белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын, Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның чикләүләрне үтәвен тикшерү турында нигезләмә яисә Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 1 ноябрендәге ПУ-711 номерлы Указы нигезендә расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан бирелә торган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәвен тикшерү турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Рәисенең Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсе (алга таба – Идарә) тарафыннан уздырылган, Комиссиягә тапшырылган тикшерү материаллары;

Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче затның, дәүләт хезмәткәренең хезмәт (вазыйфаи) тәртибенә таләпләрне һәм (яисә) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча таләпләрне үтәмәве турында Комиссиягә карап тикшерүгә бирелгән башка материаллар;

Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче затның, дәүләт хезмәткәренең чыгымнарына контроль ясау турында карар кабул иткән затның чыгымнарга контроль ясаганда алынган нәтиҗәләрне карап тикшерү турында Комиссиягә карап тикшерүгә килгән тәкъдиме;

б) карап тикшерү өчен Идарәгә килгән:

гражданның Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтеннән азат ителгән көннән ике ел узганчы, коммерциячел яисә коммерциячел булмаган

оешмада, әлеге оешмага дәүләт идарәсе буенча аерым функцияләр аның вазыйфаи бурычларына кергән очракта, вазыйфа биләүгә һәм (яисә) әлеге оешмада гражданлык-хокукый шартнамә нигезендә эш башкаруга (әлеге оешмага хезмәт күрсәтүгә) ризалык бирүе турында мөрәҗәгате;

Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче затның, дәүләт хезмәткәренең объектив сәбәпләр буенча хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр бирү мөмкинлеге булмавы турында гаризасы;

Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче затның, дәүләт хезмәткәренең чит ил территориясендәге чит ил банкында счетлары (кертемнәре) булган, акча һәм кыйммәтле әйберләре саклана торган һәм (яисә) чит ил финанс инструментлары булган әлеге чит ил законнары нигезендә аның вәкаләтле органнары тарафыннан арест салынган, алардан куллану тыелган очракта, яисә үзенең ихтыярына яки хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының ихтыярына бәйле булмаган башка шартлар сәбәпле «Аерым категориягә кергән затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм тоту, акча һәм кыйммәтле әйберләр саклау, чит ил финанс инструментларын тоту һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында» 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – «Аерым категориягә кергән затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм тоту, акча һәм кыйммәтле әйберләр саклау, чит ил финанс инструментларын тоту һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында» Федераль закон) таләпләрен үтәү мөмкинлегенең булмавы турында гаризасы;

Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче затның, дәүләт хезмәткәренең аның тарафыннан хезмәт (вазыйфаи) тәртибенә куелган таләпләрне үтәүгә һәм (яисә) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салуга куелган таләпләрне үтәүгә комачаулык итүче, аның ихтыярына бәйле булмаган сәбәпләр килеп чыгуы турында «Коррупциягә каршы көрәшү турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясы 6 кисәге нигезендә бирелгән хәбәрнамәсе;

в) вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китергән яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксыну килеп чыгу турында Татарстан Республикасы Рәисе яисә Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе карары буенча Комиссиягә килгән хәбәрнамә, шулай ук нигезле бәяләмә һәм башка материаллар;

г) «Коррупциягә каршы көрәшү турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясы 6 кисәге һәм Россия Федерациясе Хезмәт кодексының $61^1$ статьясы нигезендә коммерциячел яисә коммерциячел булмаган оешманың, әлеге оешмага дәүләт идарәсе буенча аерым функцияләр Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын биләгән вакытында гражданның вазыйфаи бурычларына кергән

очракта, аны элегрәк Комиссия тарафыннан әлеге оешма белән хезмәт һәм (яисә) гражданлык-хокукый шартнамәсе нигезендә мөнәсәбәтләр урнаштыру тыелган һәм Комиссия тарафыннан гражданга гражданлык-хокукый шартнамәсе нигезендә коммерциячел яисә коммерциячел булмаган оешмада вазыйфа биләүгә һәм (яисә) әлеге оешмада эш башкаруга (әлеге оешмага хезмәт күрсәтүгә) ризалык бирү мәсьәләсе каралмаган очракта, граждан белән хезмәт шартнамәсе һәм (яисә) әлеге оешмада эш башкаруга (әлеге оешмага хезмәт күрсәтүгә) гражданлык-хокукый шартнамә төзү турында хәбәрнамәсе.

3. Әлеге Нигезләмәнең 2 пункты «б» пунктчасында күрсәтелгән мөрәҗәгать, гаризалар, хәбәрнамә Татарстан Республикасы Рәисе исеменә бирелә.

Әлеге Нигезләмәнең 2 пункты «б» пунктчасы икенче абзацында күрсәтелгән мөрәҗәгатьтә гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), аның туган вакыты, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтеннән азат ителгәнче соңгы ике елда биләгән вазыйфалары, коммерциячел яисә коммерциячел булмаган оешманың атамасы, урнашкан урыны, аның эшчәнлеге төре, гражданның Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын биләгәндә коммерциячел яисә коммерциячел булмаган оешма белән бәйле башкарган вазыйфаи бурычлары, шартнамәнең төре (хезмәт яисә гражданлык-хокукый), аның фаразланган гамәлдә булу вакыты, шартнамә буенча башкарылган эшләр (хезмәтләр) өчен түләнә торган бәя күрсәтелә.

Әлеге Нигезләмәнең 2 пункты «б» пунктчасы өченче абзацында күрсәтелгән гариза керемнәр, чыгымнар турында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр бирү өчен билгеләнгән вакытта бирелә.

Әлеге Нигезләмәнең 2 пункты «б» – «г» пунктчаларында күрсәтелгән мөрәҗәгать, гаризалар һәм хәбәрнамәләр Идарәдә карап тикшерелә һәм аларны карап тикшерү нәтиҗәләре буенча һәрберсенә нигезле бәяләмә әзерләнә.

$3^1$. Әлеге Нигезләмәнең 3 пунктында каралган нигезле бәяләмә әзерләнгәндә Идарәнең вазыйфаи затлары Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе йөкләмәсе буенча әлеге Нигезләмәнең 2 пункты «б» һәм «в» пунктчалары нигезендә мөрәҗәгатьләр, гаризалар һәм хәбәрнамәләр биргән затлардан һәм әлеге Нигезләмәнең 2 пункты «г» пунктчасы нигезендә аларга мөнәсәбәтле рәвештә хәбәрнамәләр бирелгән затлардан билгеләнгән тәртиптә тиешле аңлатмалар таләп итәргә хокуклы, ә Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе тиешле тәртиптә федераль дәүләт органнарына, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка субъектлары дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм кызыксынган оешмаларга соратулар җибәрергә, коррупциягә каршы көрәшү өлкәсендә «Посейдон» дәүләт мәгълүмат системасын, шул исәптән соратулар юллау өчен файдаланырга мөмкин.

Мөрәҗәгать, гариза яисә хәбәрнамә, шулай ук бәяләмә һәм башка материаллар мөрәҗәгать, гариза яисә хәбәрнамә килгән көннән 30 көн эчендә Комиссия рәисенә бирелә.

Соратулар юлланган очракта мөрәҗәгать, гариза яисә хәбәрнамә, шулай ук бәяләмә һәм башка материаллар гариза яисә хәбәрнамә килгән көннән 30 көн эчендә Комиссия рәисенә бирелә. Әлеге срок озайтылырга мөмкин, ләкин ул 30 көннән дә артып китәргә тиеш түгел.

$3^2$. Әлеге Нигезләмәнең 3 пункты дүртенче абзацында каралган нигезле бәяләмәдә түбәндәгеләр булырга тиеш:

а) әлеге Нигезләмәнең 2 пункты «б» – «г» пунктчаларында күрсәтелгән мөрәҗәгатьтә, гаризаларда һәм хәбәрнамәләрдә бәян ителгән мәгълүмат;

б) соратулар нигезендә федераль дәүләт органнарыннан, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка субъектлары дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан һәм кызыксынган оешмалардан алынган мәгълүмат;

в) әлеге Нигезләмәнең 2 пункты «б» – «г» пунктчаларында күрсәтелгән мөрәҗәгатьне, гаризаларны һәм хәбәрнамәләрне алдан карап тикшерү нәтиҗәләре буенча нигезле йомгак, шулай ук әлеге Нигезләмәнең $14^1$–$15^3$ пунктлары нигезендә карарларның берсен кабул итү өчен тәкъдимнәр.

$3^3$. Әлеге Нигезләмәнең 2 пункты «б» пунктчасы өченче абзацында күрсәтелгән гаризада һәм аны карап тикшерү нәтиҗәсендә әзерләнгән нигезле бәяләмәдә Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче затка, дәүләт хезмәткәренә керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр бирмәвенең сәбәбе объектив һәм дәлилле дип танылган тиешле нигезләр булганда, Комиссия рәисе әлеге Нигезләмәнең 15 пункты «а» пунктчасында каралган карарны кабул итәргә мөмкин.

Әлеге Нигезләмәнең 2 пункты «б» пунктчасы дүртенче абзацында күрсәтелгән гаризада һәм аны карап тикшерү нәтиҗәсендә әзерләнгән нигезле бәяләмәдә «Аерым категориягә кергән затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм тоту, акча һәм кыйммәтле әйберләр саклау, чит ил финанс инструментларын тоту һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында» Федераль закон таләпләрен үтәүгә комачаулык итүче шартларны объектив дип нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирүче тиешле нигезләр булган очракта, Комиссия рәисе әлеге Нигезләмәнең $15^1$ пункты «а» пунктчасында каралган карарны кабул итәргә мөмкин.

Әлеге Нигезләмәнең 2 пункты «в» пунктчасында күрсәтелгән гаризада һәм аны карап тикшерү нәтиҗәсендә әзерләнгән нигезле бәяләмәдә хәбәрнамә биргән зат вазыйфаи бурычларын үтәгән вакытта мәнфәгатьләр каршылыгы килеп чыкмый дип нәтиҗә ясар өчен тиешле дәлилләр булган

очракта, Комиссия рәисе әлеге Нигезләмәнең $15^2$ пункты «а» пунктчасында каралган карарны кабул итәргә мөмкин.

Әлеге Нигезләмәнең 2 пункты «б» пунктчасы бишенче абзацында күрсәтелгән хәбәрнамәдә һәм аны карап тикшерү нәтиҗәсендә әзерләнгән нигезле бәяләмәдә хәбәрнамә биргән зат йогынты ясый алмый торган шартларның барлыкка килүе һәм аның хезмәт (вазыйфаи) тәртибенә таләпләрне үтәүгә һәм (яисә) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салуга таләпләрне үти алмавы арасында сәбәп-нәтиҗә бәйләнеше бар дип нәтиҗә ясар өчен тиешле дәлилләр булган очракта, Комиссия рәисе әлеге Нигезләмәнең $15^2$ пункты «а» пунктчасында каралган карарны кабул итәргә мөмкин.

Комиссия рәисе карары белән нигезле бәяләмә һәм аның нигезендә кабул ителгән карар Комиссиянең чираттагы утырышында Комиссия әгъзаларына җиткерелә. Мөрәҗәгать, гариза яисә хәбәрнамә биргән затка карар кабул ителгән көннән 15 көн эчендә язма рәвештә кабул ителгән карар турында хәбәр ителергә тиеш.

4. Әлеге Нигезләмәнең 2 пунктында күрсәтелгән мәсьәләләр карап тикшерелә торган Комиссия утырышын уздыру көне һәм аны уздыру урыны Комиссия рәисе тарафыннан билгеләнә.

5. Комиссия секретаре Комиссия утырышында карап тикшерелә торган мәсьәләләрне әзерләүне тәэмин итә, шулай ук Комиссия әгъзаларына һәм Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасы биләүче затка, дәүләт хезмәткәренә яисә гражданга Комиссия утырышының көн тәртибенә кертелгән мәсьәләләр, утырыш уздыру урыны турында утырыш уздырыласы көнгә кадәр 7 көн алдан хәбәр итүне оештыра.

6. Комиссия әгъзаларының гомуми саныннан кимендә өчтән икесе катнашкан очракта, Комиссия утырышы гамәлгә хокуклы санала.

7. Комиссиянең барлык әгъзалары карар кабул иткәндә тигез хокукка ия була.

8. Комиссия утырышында Комиссия әгъзаларының берсенең хезмәт (вазыйфаи) тәртибенә таләпләрне үтәве һәм (яисә) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салуга таләпләрне үтәвенә кагылышлы мәсьәлә карап тикшерелгән очракта, Комиссиянең әлеге әгъзасы әлеге Нигезләмәнең $13–15^4$ пунктларында каралган карар кабул иткәндә тавыш бирү хокукына ия булмый.

9. Комиссия утырышы, кагыйдә буларак, әлеге Нигезләмәнең 2 пункты «б» һәм «в» пунктчалары нигезендә мөрәҗәгать, гариза һәм хәбәрнамә биргән зат катнашында уза. Комиссия утырышында шәхсән катнашырга теләге булуы турында мөрәҗәгать, гариза һәм хәбәрнамә биргән зат мөрәҗәгатьтә, гаризада һәм хәбәрнамәдә күрсәтә.

$9^1$. Комиссия утырышы түбәндәге очракларда әлеге Нигезләмәнең 2 пункты «б» һәм «в» пунктчалары нигезендә мөрәҗәгать, гариза һәм хәбәрнамә биргән зат катнашыннан башка уздырыла:

а) мөрәҗәгать, гариза һәм хәбәрнамә биргән зат мөрәҗәгатьтә, гаризада һәм хәбәрнамәдә Комиссия утырышында шәхсән катнашырга теләге булуын белдермәгәндә;

б) Комиссия утырышында шәхсән катнашырга теләге булган һәм Комиссия утырышы уздыру вакыты һәм урыны турында тиешле рәвештә хәбәр ителгән мөрәҗәгать, гариза һәм хәбәрнамә биргән зат Комиссия утырышына килмәгәндә.

10. Комиссия рәисе карары нигезендә Комиссия утырышына Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары, кызыксыну белдергән башка органнар һәм оешмалар вәкилләре чакырыла ала.

11. Комиссия рәисе тарафыннан билгеләнгән тәртиптә Комиссия утырышында Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасы биләүче затның, дәүләт хезмәткәренең яисә гражданның аңлатмалары тыңлана һәм утырышның көн тәртибенә кертелгән мәсьәләләргә кагылышлы материаллар карап тикшерелә. Комиссия утырышында Комиссия әгъзаларының, Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасы биләүче затның, дәүләт хезмәткәренең яисә гражданның үтенече буенча башка затлар да чыгыш ясарга мөмкин һәм алар тарафыннан бирелгән материаллар да карап тикшерелә ала.

12. Комиссия әгъзалары һәм утырышта катнашкан затлар аларга Комиссия эше барышында билгеле булган мәгълүматларны таратырга тиеш түгел.

13. Әлеге Нигезләмәнең 2 пункты «а» пунктчасының икенче һәм өченче абзацлары нигезендә материалларны карап тикшерү нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итәргә мөмкин:

а) карап тикшерелә торган очракта Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасы биләүче зат, дәүләт хезмәткәре тарафыннан хезмәт (вазыйфаи) тәртибенә таләпләрнең һәм (яисә) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салуга таләпләрнең үтәлмәвен күрсәтүче билгеләр юк дип билгеләргә;

б) карап тикшерелә торган очракта Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасы биләүче зат, дәүләт хезмәткәре тарафыннан хезмәт (вазыйфаи) тәртибенә таләпләрнең һәм (яисә) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салуга таләпләрнең үтәлмәвен күрсәтүче билгеләр бар дип билгеләргә.

14. Әлеге Нигезләмәнең 2 пункты «а» пунктчасының дүртенче абзацы нигезендә тәкъдимне карап тикшерү нәтиҗәсендә Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасы биләүче затка, дәүләт хезмәткәренә карата юридик җаваплылыкка тарту чарасын куллану (яисә кулланмау) турында тәкъдим булган карар кабул ителә.

14[1]. Әлеге Нигезләмәнең 2 пункты «б» пунктчасының икенче абзацы нигезендә мөрәҗәгатьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итәргә мөмкин:

а) гражданга коммерциячел яисә коммерциячел булмаган оешмада, әлеге оешмага дәүләт идарәсе буенча аерым функцияләр аның вазыйфаи

бурычларына кергән очракта, вазыйфа биләүгә һәм (яисә) әлеге оешмада гражданлык-хокукый шартнамә нигезендә эш башкаруга (әлеге оешмага хезмәт күрсәтүгә) ризалык бирү;

б) гражданга коммерциячел яисә коммерциячел булмаган оешмада, әлеге оешмага дәүләт идарәсе буенча аерым функцияләр аның вазыйфаи бурычларына кергән очракта, вазыйфа биләүгә һәм (яисә) әлеге оешмада гражданлык-хокукый шартнамә нигезендә эш башкаруга (әлеге оешмага хезмәт күрсәтүгә) ризалык бирүдән баш тарту һәм аның сәбәпләрен нигезләү.

15. Әлеге Нигезләмәнең 2 пункты «б» пунктчасының өченче абзацы нигезендә гаризаны карап тикшерү нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итәргә мөмкин:

а) Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче затның, дәүләт хезмәткәренең хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр бирү мөмкинлеге булмавының сәбәбен объектив һәм дәлилле дип тану;

б) Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче затның, дәүләт хезмәткәренең хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр бирү мөмкинлеге булмавының сәбәбе дәлилле түгел дип тану. Бу очракта Комиссия Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче затка, дәүләт хезмәткәренә әлеге белешмәләрне бирү чараларын күрергә тәкъдим итә;

в) Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче затның, дәүләт хезмәткәренең хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр бирү мөмкинлеге булмавының сәбәбе объектив түгел һәм әлеге гамәлне белешмәләрне бирүдән баш тарту ысулы дип тану.

15[1]. Әлеге Нигезләмәнең 2 пункты «б» пунктчасының дүртенче абзацы нигезендә гаризаны карап тикшерү нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итәргә мөмкин:

а) Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче затның, дәүләт хезмәткәренең «Аерым категориягә кергән затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм тоту, акча һәм кыйммәтле әйберләр саклау, чит ил финанс инструментларын тоту һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында» Федераль закон таләпләрен үтәү мөмкинлегенә комачаулык итүче сәбәпләрне объектив дип тану;

б) Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче затның, дәүләт хезмәткәренең «Аерым категориягә кергән затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм тоту, акча һәм кыйммәтле әйберләр саклау, чит ил финанс

инструментларын тоту һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында» Федераль закон таләпләрен үтәү мөмкинлегенә комачаулык итүче сәбәпләрне объектив түгел дип тану.

15[2]. Әлеге Нигезләмәнең 2 пункты «в» пунктчасының дүртенче абзацы нигезендә хәбәрнамәне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итәргә мөмкин:

а) хәбәрнамә биргән затның вазыйфаи бурычларын үтәве мәнфәгатьләр каршылыгына китерми дип тану;

б) хәбәрнамә биргән затның вазыйфаи бурычларын үтәгәндә барлыкка килгән шәхси кызыксынганлыгы мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яисә китерергә мөмкин дип тану. Бу очракта Комиссия хәбәрнамә биргән затка мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау яисә җайга салу буенча чаралар күрергә тәкъдим итә;

в) хәбәрнамә биргән зат тарафыннан мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу таләпләре үтәлмәгән дип тану. Кабул ителгән карар турында Комиссия рәисе яисә Комиссия секретаре Россия Федерациясе законнарында каралган юридик җаваплылыкка тарту чараларын куллануга вәкаләтле дәүләт органы яисә оешманың вазыйфаи затына хәбәр итә.

15[3]. Әлеге Нигезләмәнең 2 пункты «в» пунктчасының бишенче абзацы нигезендә хәбәрнамәне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итәргә мөмкин:

а) хәбәрнамә биргән зат йогынты ясый алмый торган шартларның барлыкка килүе һәм аның хезмәт (вазыйфаи) тәртибенә таләпләрне үтәүгә һәм (яисә) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салуга таләпләрне үти алмавы арасында сәбәп-нәтиҗә бәйләнеше бар дип тану;

б) хәбәрнамә биргән зат йогынты ясый алмый торган шартларның барлыкка килүе һәм аның хезмәт (вазыйфаи) тәртибенә таләпләрне үтәүгә һәм (яисә) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салуга таләпләрне үти алмавы арасында сәбәп-нәтиҗә бәйләнеше юк дип тану.

15[4]. Әлеге Нигезләмәнең 2 пункты «г» пунктчасы нигезендә хәбәрнамәләрне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итәргә мөмкин:

а) гражданга коммерциячел яисә коммерциячел булмаган оешмада вазыйфа биләүгә һәм (яисә) әлеге оешмада гражданлык-хокукый шартнамә нигезендә эш башкаруга (әлеге оешмага хезмәт күрсәтүгә) ризалык бирү;

б) гражданның коммерциячел яисә коммерциячел булмаган оешмада вазыйфа биләве һәм (яисә) әлеге оешмада гражданлык-хокукый шартнамә нигезендә эш башкаруы (әлеге оешмага хезмәт күрсәтүе) «Коррупциягә каршы көрәшү турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 12 статьясы таләпләрен бозуга китерә дип билгеләргә. Комиссия дәүләт органы җитәкчесенә бу турыда прокуратура органнарына һәм хәбәрнамә биргән оешмага хәбәр итәргә тәкъдим итә.

15[5]. Комиссия әлеге Нигезләмәнең 13–15[4] пунктларында каралган карарлардан тыш башка карарлар кабул итәргә хокуклы. Әлеге карарны

кабул итүнең нигезләре һәм аны кабул итүгә этәргән сәбәпләр Комиссия утырышы беркетмәсендә күрсәтелергә тиеш.

16. Комиссия тарафыннан Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче затның, дәүләт хезмәткәренең административ хокук бозу яисә җинаять кылу билгеләре булган гамәл кылуы (гамәл кылмавы) факты ачыкланган очракта, Комиссия секретаре Комиссия рәисе кушуы буенча әлеге гамәл (гамәл кылмау) турында мәгълүматны һәм әлеге фактны раслаучы документларны административ хокук бозулары турында эш кузгатуга һәм җинаять кылу турында мәгълүматны карап тикшерүгә вәкаләтле органнарга юллый.

17. Комиссия карарлары утырышта катнашкан Комиссия әгъзаларының гади күпчелеге тавышы белән коллегиаль төстә кабул ителә. Тавышлар саны тигез булганда, Комиссия рәисенең тавышы хәлиткеч санала.

18. Комиссия карары Комиссия рәисе һәм Комиссия секретаре тарафыннан кул куела торган беркетмә белән рәсмиләштерелә.

18[1]. Әлеге Нигезләмәнең 2 пункты «б» һәм «в» пунктчалары нигезендә мөрәҗәгатьтә, гаризаларда һәм хәбәрнамәләрдә аларны биргән затның Комиссия утырышында шәхсән катнашырга теләге булуы күрсәтелмәгән очракта, шулай ук әлеге Нигезләмәнең 2 пункты «г» пунктчасында каралган хәбәрнамә карап тикшерелгәндә, Комиссия утырышында әлеге мөрәҗәгатьләрне, гаризаларны һәм хәбәрнамәләрне карап тикшерү белән бәйле мәсьәләләр буенча тавыш бирү Комиссия рәисе карары буенча Комиссия әгъзаларына сораштыру кәгазьләре һәм башка материаллар юллап, читтән торып та үткәрелергә мөмкин.

Сораштыру кәгазен тутырган вакытта Комиссия әгъзасы Комиссия тарафыннан тәкъдим ителгән карар буенча, аны хуплап яисә каршы тавыш биреп, һичшиксез, үз фикерен белдерергә тиеш. Комиссия әгъзасы тарафыннан кул куелган сораштыру кәгазе аны алган көннән өч эш көне эчендә Комиссиягә җибәрелергә тиеш.

Читтән торып тавыш бирү нәтиҗәләре буенча кабул ителгән Комиссия карары әлеге Нигезләмәнең 19 пункты таләпләре нигезендә беркетмә белән рәсмиләштерелә һәм аңа кул куелган көннән җиде эш көне эчендә Комиссия әгъзаларына һәм кызыксыну белдергән затларга юллана.

19. Комиссия утырышы беркетмәсендә түбәндәгеләр күрсәтелә:

а) Комиссия утырышы датасы, утырышта катнашкан Комиссия әгъзаларының һәм башка затларның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта);

б) Комиссия утырышында карала торган һәрбер мәсьәләне, аның белән бәйле мәсьәлә карап тикшерелгән Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасы биләүче затның, дәүләт хезмәткәренең яисә гражданның фамилиясен, исемен, атасының исемен (булган очракта), биләгән вазыйфасын күрсәтеп, бәян итү;

в) Комиссия утырышы уздыру өчен нигезләр булган мәгълүмат чыганагы, әлеге мәгълүматның Идарәгә керү датасы;

г) Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасы биләүче затның, дәүләт хезмәткәренең яисә гражданның карап тикшерелә торган мәсьәләләрнең асылы буенча аңлатмасының эчтәлеге;

д) утырышта чыгыш ясаган затларның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта) һәм аларның чыгышларының кыскача эчтәлеге;

е) башка мәгълүматлар;

ж) тавыш бирү йомгаклары;

з) Комиссия карары һәм аны кабул итү өчен нигезләр.

20. Кабул ителгән карар белән риза булмаган Комиссия әгъзасы үзенең аерым фикерен язма рәвештә бәян итәргә хокуклы, ул мәҗбүри рәвештә Комиссия утырышы беркетмәсенә кертелергә тиеш.

21. Комиссия карарыннан өземтә аның белән бәйле мәсьәлә карап тикшерелгән Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасы биләүче затка, дәүләт хезмәткәренә яисә гражданга, шулай ук аны вазыйфага билгеләүгә (сайлап куюга, раслауга) вәкаләтле вазыйфаи затка (Татарстан Республикасы дәүләт органына) Комиссия утырышы беркетмәсенә кул куелган көннән биш эш көне эчендә юллана.

22. Комиссия карарына Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә шикаять белдерергә мөмкин.».

6. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы аерым дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерүче яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынганлыгы барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибе хакында һәм Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү турында» 2016 елның 18 мартындагы ПУ-265 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2022 елның 20 декабрендәге ПУ-905 номерлы Указы һәм Татарстан Республикасы Рәисенең 2023 елның 23 сентябрендәге 667 номерлы Указы нигезендә кертелгән үзгәреше белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) атамада «Татарстан Республикасы аерым дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның,» сүзләреннән соң «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын,» сүзләрен өстәргә;

б) 1 пунктта «Татарстан Республикасы аерым дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның,» сүзләреннән соң «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын,» сүзләрен өстәргә;

в) Татарстан Республикасы аерым дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерүче яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынганлыгы барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибе хакында нигезләмәдә:

атамада «Татарстан Республикасы аерым дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның,» сүзләреннән соң «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын,» сүзләрен өстәргә;

1 пунктта «Татарстан Республикасы аерым дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның,» сүзләреннән соң «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын,» сүзләрен өстәргә;

2 пунктта «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар,» сүзләреннән соң «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын,» сүзләрен өстәргә;

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Кушымта нигезендәге форма буенча төзелгән хәбәрнамә Татарстан Республикасы Рәисенә түбәндәгеләр тарафыннан җибәрелә:

Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар: Татарстан Республикасы Премьер-министры, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе, Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасары, Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы министры, Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Россия Федерациясендә Татарстан Республикасының Вәкаләтле вәкиле, Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты Җитәкчесе, Татарстан Республикасы министры, Татарстан Республикасы дәүләт комитеты рәисе, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең башка органы җитәкчесе – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты әгъзасы, Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча Вәкаләтле вәкил, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил, Татарстан Республикасы Хисап палатасы Рәисе, Татарстан Республикасы Хисап палатасы Рәисе урынбасары, Татарстан Республикасы Хисап палатасы аудиторы, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе Рәисе, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе Рәисе урынбасары, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе секретаре, Татарстан Республикасы Конституция советы Рәисе, Татарстан Республикасы Конституция советы әгъзасы;

Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан вазыйфага билгеләп куела һәм вазыйфадан азат ителә торган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең аерым вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан: Татарстан Республикасының Россия Федерациясе субъектындагы, БДБ илләрендәге, чит илләрдәге вәкиле, Татарстан Республикасының Россия Федерациясендәге Вәкаләтле вәкиленең беренче урынбасары, Татарстан Республикасының Россия Федерациясе субъектындагы, БДБ илләрендәге, чит илләрдәге вәкиле урынбасары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты составына керми торган республика башкарма хакимият органы җитәкчесе.»;

12 пунктта «Татарстан Республикасында Коррупциягә каршы көрәшү эшен координацияләү комиссиясенең Татарстан Республикасы дәүләт

вазыйфаларын биләүче затларның хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәвенә һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салуга кагылышлы мәсьәләләрне карау тәртибе турындагы нигезләмәдә» сүзләрен «Татарстан Республикасында Коррупциягә каршы көрәшү эшен координацияләү комиссиясенең Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең кайбер вазыйфаларын биләүче затларның хезмәт (вазыйфаи) тәртибенә таләпләрне үтәвенә һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салуга, шулай ук гражданнарның һәм оешмаларның кайбер мөрәҗәгатьләренә кагылышлы мәсьәләләрне карау тәртибе турындагы нигезләмәдә».

7. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2025 ел, 12 май
№ 354